**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Алькеевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2023 елның 28 феврале 57№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 18 декабрендәге «2021-2023 елларга Әлки муниципаль районында физик тәрбия һәм спортны үстерү» озак сроклы район максатчан программасын раслау турында» 518 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы «2019 - 2023 елларга Татарстан Республикасында физик тәрбия һәм спортны үстерү» озак сроклы максатчан программасы турында» 159 номерлы карары нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 18 декабрендәге «2021-2023 елларга Әлки муниципаль районында физик тәрбия һәм спортны үстерү» озак сроклы район максатчан программасын раслау турында» 518 номерлы карары (2021.20.10, 536а№ ред.) нигезендә расланган «2019 - 2023 елларга Татарстан Республикасында физик тәрбия һәм спортны үстерү» программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«2021-2023 елларга Әлки муниципаль районында физик тәрбия һәм спортны үстерү» озак сроклы район максатчан программасын гамәлгә ашыру буенча чаралар» кушымтасына түбәндәге эчтәлекле 36 пункт өстәргә:

| № | Чаралар исеме | Җаваплы башкаручы | Башкару вакыты | Сумма-мең сум | Финанслау чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|
| 36 | Әлки муниципаль районының «Спорт мәктәбе» МБУ өчен спорт җиһазлары, инвентарьлар һәм экипировка сатып алу | Әлки муниципаль районының «Спорт мәктәбе» МБУ | 2023г | 175,360 | РБ |

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми https://alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгарырга һәм "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми http://pravo.tatarstan.ru порталы"нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: Р.Х. Морадымов

Вәлиев А.А.